ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **К А Р А Р**

25.02.2026 | № 209

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карарына (2018 елның 13 сентябрендәге № 1998, 21.05.2019 № 710, 10.02.2022 № 212, 22.01.2025 №79 карарлар редакциясендә) түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «һәм Аппаратның вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси кабул итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Карарның 1 пунктында «һәм Аппаратның вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси кабул итү» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның

мөрәҗәгатьләрен карау, шәхсән кабул итү тәртибе исемендә «һәм аппаратның вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарны шәхсән кабул итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 1.1 пунктында «һәм шәхси кабул итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3. 2 бүлекнең 2.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Граждан мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яки "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - Бердәм порталын), "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен (әлеге Федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса) тәэмин итә торган дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасын йә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелгән тәкъдим, гариза яисә шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;»

2.4. 4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.4 пункт белән тулыландырырга:

«4.4. Оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясе иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына аларның мөрәҗәгать итүләренә бәйле рәвештә гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, дәүләт саклау өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар, хәбәрнамәләр җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.»;

2.5. 5 бүлекнең 5.2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2 Граждан үзенең мөрәҗәгатендә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысын - булган очракта) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, шулай ук алар буенча җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда яисә гражданның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасында шәхси кабинет адресын (уникаль идентификаторын) файдалана. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада кушып бирергә хокуклы.»;

2.6. 6 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 6.27. пункт белән тулыландырырга:

«6.27. Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ формасында дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча, яисә Бердәм порталдан яисә башка мәгълүмати системадан файдаланганда, гражданның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган Бердәм порталдагы яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмати системасындагы гражданның шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы) буенча һәм дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.».

2.7. 10 бүлекне төшереп калдырырга

2.8. 11 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

**«11. Гражданнарның «турыдан-туры линияләр», «кайнар линияләр» телефоннары һәм махсус ышаныч тартмасы аша кабул ителгән мөрәҗәгатьләрен карау**

11.1. Җирле үзидарә органнары халык белән муниципаль хакимият арасында өстәмә элемтә коралы, гражданнарның үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат алу хокукының ачыклыгын тәэмин итү һәм гамәлгә ашыру максатларында "турыдан-туры линияләр", "кайнар линияләр" һәм махсус ышаныч тартмасы эшен оештыралар.

11.2. Гражданнарның "турыдан-туры линияләр" һәм "кайнар линияләр" телефоннары аша мөрәҗәгатьләрен кабул итүгә вәкаләтле органның вазыйфаи заты гражданның гаризасын, тәкъдимен яисә шикаятен телдән мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында 3 нче кушымта нигезендә терки һәм, мөрәҗәгать итүченең шәхси белешмәләрен, контакт телефонын һәм (яисә) электрон почта адресын (алар булганда), мәсьәләнең асылын, мөрәҗәгатьнең керү датасын һәм вакытын тутырып, электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасында мөрәҗәгатьнең электрон карточкасын формалаштыра.

11.3. "Турыдан-туры линияләр" һәм "кайнар линияләр" эше район Советы кабул итә торган норматив хокукый актлар һәм әлеге Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

11.4. «Кайнар линия» телефоннары:

гомуми мәсьәләләр буенча – 8 (84365) 2-30-61;

коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча (84365) 2-30-67.

рәсми булмаган мәшгульлекне киметү һәм хезмәт мөнәсәбәтләрен легальләштерү мәсьәләләре буенча - (84365) 2-30-55.

11.5. Махсуслаштырылган ышаныч тартмасы гражданнар өчен уңайлы урында - Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.юл ст. пос., Кооператив ур., 5 й., адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы администрациясе бинасында бинаның керү төркемендә урнаштырыла.

11.6. Махсус тартма урнашу урыны, эшләве һәм эш режимы турында мәгълүмат Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә урнаштырыла.

11.7. Махсус тартмадан гражданнар дүшәмбедән пәнҗешәмбегә кадәр эш көннәрендә 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, җомга көнне 08.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр файдалана ала.

11.8. Кергән мөрәҗәгатьләрдән рөхсәтсез файдалану, шулай ук аларны юк итү мөмкинлеген булдырмау максатларында махсус тартмага мөһер сугыла.

11.9. Махсус тартмада түбәндәге эчтәлекле текстлы вывеска урнаштырыла: «Гаризалар, тәкъдимнәр һәм шикаятьләр өчен».

11.10. Махсус тартма идәннән 0,85 – 1,1 м биеклектә урнаштырыла, тартма янында корреспонденцияне алу графигы турында мәгълүмат, гариза язу үрнәге, элемтә телефон номеры, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләр җавапсыз калдырылырга мөмкин булуы турында хәбәр урнаштырыла.

11.11. Махсус тартманы ачу һәм мөрәҗәгатьләрне алу гомуми бүлек хезмәткәрләре тарафыннан көн саен, дүшәмбедән пәнҗешәмбегә кадәр 11.00 сәгатьтә, җомга көнне 16.00 сәгатьтә башкарыла, бу хакта журналга 4 нче кушымта нигезендә язма язып куела.

11.12. Гаризалар, тәкъдимнәр һәм шикаятьләр ышаныч тартмасыннан алу көнендә теркәлә.

11.13. «Турыдан-туры линияләр», «кайнар линияләр» телефоннары һәм махсус ышаныч тартмасы аша кабул ителгән гаризаларны, тәкъдимнәрне һәм шикаятьләрне теркәү һәм карау гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре өчен Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм әлеге Тәртиптә башкарыла.»

2.9. 13 бүлекнең 13.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«13.4. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләренә анализ хисап чорыннан соң килә торган айның 20 числосыннан да соңга калмыйча елга ике тапкыр (яртыеллыкларда) башкарыла һәм Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

4 нче кушымта
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
25.02.2026 209нче номерлы
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнә гражданнардан һәм оешмалардан кергән язма гаризаларны, шикаятьләрне, тәкъдимнәрне ачу һәм алу (махсус ышаныч тартмасы)
ЖУРНАЛЫ

| № т/б | Алу датасы | Алу вакыты | Әрҗә һәм пломбаның торышы (бөтенлеге) | Алынган хатлар саны (данә) | Җаваплы затның ФИО һәм имзасы | Катнашучының ФИО һәм имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |